**СОВЕТ КУТЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Клубная, д.1а, село Кутема, 423112

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КҮТӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Клуб урамы, 1а йорты, Күтәмә авылы, 423112

тел.+7(84396) 4-30-88, e-mail: Kut.Cmn2@tatar.ru

№ 139 06 март 2025 ел

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 6 февралендәге №118 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 6 февралендәге 118 номерлы карарына (Советның 13.06.2019 ел, №128, 30.09.2021 ел, №39, 23.08.2024 ел, №118, 26.12.2024 ел, №133 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның 14 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «Салым ташламасы бирелә торган сайланган салым салу объектлары турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан салым органына үз теләге белән күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган салым чоры булган елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча тапшырыла. Сайланган салым салу объектлары турында хәбәрнамә салым органына дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырылырга мөмкин».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Күтәмә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **Н.Г. Сабиров**